| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.04.2024 Казан ш № 241

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 19.07.2016 №412, 08.06.2017 №348, 25.01.2018 №60, 07.05.2018 № 348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 14.11.2019 №1016, 07.02.2020 №80, 01.09.2020 №605, 22.12.2020 №885, 02.06.2021 №385, 06.08.2021 №564, 01.10.2021 №709, 30.05.2022 №437,

07.11.2022 №988, 29.06.2023 №510 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, (кушымтада бирелгән) яңа редакциядә бәян итәргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 22.09.2015 №670 боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның 03 апрелендәге 241 номерлы боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр:

аз керемле гаиләләр һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданнар, аларның җан башына исәпләгәндә уртача кереме «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән бер кешегә яшәү минимумы (алга таба – җан башына яшәү минимумы күләме) күләменнән түбәнрәк булса, әгәр аз керемле гаилә әгъзалары һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданин яше, сәламәтлеге буенча хезмәткә сәләтсез булып торса;

авыр тормыш хәлендә калган, бердәнбер торак һәм (яки) мөлкәте янгын, су басу яки башка табигый афәт нәтиҗәсендә зыян күргән һәм уртача җан башына кереме аена 20 000 сумнан артмаган гаиләләр (ялгыз яшәүче гражданнар);

алардан бәйсез сәбәпләр аркасында, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү датасына җан башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләр һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданнар.

Социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме әлеге пунктның икенче-өченче абзацларында күрсәтелгән затлар категорияләренә күрсәтелә.

Әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән затлар категорияләренә дәүләт социаль ярдәме социаль контракт нигезендә күрсәтелә.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән затлар категорияләренә дәүләт социаль ярдәме әлеге гадәттән тыш хәл дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында гариза биргән айга кадәр 12 айдан да соңга калмыйча булган очракта күрсәтелә.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) (алга таба – дәүләт социаль ярдәме күрсәтү).

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында социаль яклау идарәсе (бүлеге) аша (алга таба – Идарә (бүлек), Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны яки тору урыны буенча гамәлгә ашырыла.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә. Нәтиҗәне кәгазьдә теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.2. Мөрәҗәгать итүчегә социаль ярдәм күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү сайлап алынган ысулга туры китереп рәсмиләштерелә һәм җибәрелә:

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы»

федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасындагы (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы) шәхси кабинетына җибәреп.

2.3.3. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар реквизитлары:

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.3.4. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар реквизитлары:

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.3.5. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүдән баш тарту турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

2.3.6. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә КФҮ аша апшырылган булса, гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар Идарәдә (бүлектә) теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә күрсәтелә;

гражданин тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру, эш эзләү өчен социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә КФҮ аша тапшырылган очракта, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә;

шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында эшчәнлек башкару), шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә КФҮ аша тапшырган очракта, гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар Идарәдә (бүлектә) теркәлгән көннән алып 30 эш көне эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша юллап тапшырылган булса, Идарә (бүлек) тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып ун эш көне эчендә күрсәтелә;

гражданин тарафыннан авыр тормыш хәлен җиңеп чыгуга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру, эш эзләү өчен социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар Идарәдә (бүлектә) теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә;

шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында эшчәнлек башкару), шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәрелгән очракта, гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар Идарәдә (бүлектә) теркәлгән көннән алып 30 эш көне эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте, әгәр:

социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Идарә (бүлек) тарафыннан дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә;

эш эзләү, гражданин тарафыннан авыр тормыш шартларын җиңеп чыгуга юнәлдрелегән башка чараларны гамәлгә ашыру турында социаль контракт нигезендә социаль ярдәм күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Идарә (бүлек) тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап ун эш көне эчендә күрсәтелә;

шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (эшчәнлекне «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында эшчәнлекне) гамәлгә ашыру буенча социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша бирелгән булса, Идарә (бүлек) тарафыннан, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетта чагылдырып, «Документларны тикшерү» статусы бирелгәч һәм эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән башлап 30 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт социаль ярдәмен, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында хәбәр итү дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрелгән мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында сорап шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар күчермәсен, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Идарә (бүлек), шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр):

дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча кәгазь документ рәвешендә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәме турында» федераль закон белән билгеләнмәгән өлештә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме федераль бюджеттан финанслашу шартларында Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы карары) белән расланган форма буенча кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

Россия Федерациясе халкы турында мәгълүматлар булган бердәм федераль мәгълүмат регистрында мәгълүматлар булмаганда, туу турында таныклык (тиешле акт язуын чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта);

Россия Федерациясе халкы турында мәгълүматлар булган бердәм федераль мәгълүмат регистрында мәгълүматлар булмаганда, үлем турында таныклык (тиешле акт язуын чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта);

Россия Федерациясе халкы турында мәгълүматлар булган бердәм федераль мәгълүмат регистрында мәгълүматлар булмаганда, өйләнешү (аерылышу) турында таныклык (тиешле акт язуын чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта);

үзенә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында документлар (опека (попечительлек) чит илнең вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан билгеләнгән очракта);

Россия Федерациясе Җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль иминлек хезмәте органнары, Россия Федерациясе дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлеге белән бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренең керемнәре турында документлар (Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләреннән тыш);

хәрби хезмәт, Россия Федерациясе җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, Федераль иминлек хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә хезмәт уза торган (узган) затлар тарафыннан алына торган пенсия күләме турында документлар;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында документлар, шулай ук оешма белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә;

банкларда кертемнәр буенча процентлар (счетлардагы калдыклар) рәвешендә керемнәр турында документлар;

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында документлар;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр һәм лицензия шартнамәләре буенча алынган керемнәр турында документлар;

күчемсез милекне сатудан салым салына торган керемнәр, шулай ук милекне арендага бирүдән (наем, поднаем) кергән керемнәр турында документлар;

алына торган алиментлар турында документлар (акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән очрактан тыш);

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча белем алу һәм стипендия алу (алмау) факты турында документлар;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының тулы дәүләт тәэминатында булуы турында документлар;

мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында, шулай ук хәрби һөнәри оешмада һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмасында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән затның хәрби хезмәткәр статусы турында документлар;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында документлар;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендияләр, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләренең күләме хакында документлар;

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында документлар;

дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган компенсация суммасы турында документлар;

Россия Федерациясеннән читтә чыганаклардан алынган керем суммалары турында документлар;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында документлар;

алынган грантлар, субсидияләр һәм эшкуарлыкка ярдәм итү кысаларында бирелә торган максатчан чыгымнарга ия булган башка керемнәр турында документлар;

хәбәрсез югалган дип танылган яки үлгән дип игълан ителгән кешеләр турында документлар;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының эзләнелүдә булуы турында документлар;

«Шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру» чарасы буенча социаль контрактны гамәлгә ашыру максатларында бизнес-план;

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару» чарасы буенча социаль контрактны гамәлгә ашыру максатларында чыгымнар сметасы.

Янгын, су басу яки башка табигать афәте нәтиҗәсендә авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә дәүләт социаль ярдәмен алу өчен мөрәҗәгать иткән очракта, мондый хәлләрнең килеп чыгуын раслаучы документлар өстәмә рәвештә тапшырыла:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан янгынның билгеле бер төренә карата килеп чыгуын раслаучы белешмә;

зыян күргән объектны су басу яки башка табигать афәте нәтиҗәсендә тикшерү акты, нәтиҗәсе яки белешмәсе, зыян күргән торак һәм (яки) милек урнашкан урын буенча җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

2.6.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

күпфункцияле үзәк аша кәгазьдә һәм «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) закон таләпләре нигезендә, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан, шул исәптән нотариус тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә;

Идарәгә (бүлеккә) шәхсән яисә почта аша кәгазьдә җибәреп;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша (алга таба – «Интернет» челтәре).

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек), күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ аша алырга мөмкин. Гариза кәгазенең электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) урнаштырылган.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүчеләр, гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БМАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.4. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

туу турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

туу турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

үлем турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

үлем турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә кору (аерылышу) турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә кору (аерылышу) турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

опека һәм попечительлек органының балага опека яки попечительлек билгеләү турындагы карарында булган мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан опека (попечительлек) билгеләнгән очрактан тыш) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында мәгълүмат, ата-ана хокукларын чикләүне бетерү турында мәгълүмат, баланың тормышына яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

баланың эшчәнлек сәләтен чикләү яки ата-анасын яки башка законлы вәкилен эшкә сәләтсез дип тану турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

мәҗбүри пенсия иминияте турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда үлгән иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

уртача җан башына керем исәп-хисап чорында эшкә сәләтсез затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән кайгыртуны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында белешмәләр, шулай ук оешма белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә (Федераль салым хезмәтеннән);

банкларда кертемнәр буенча процентлар (счетлардагы калдыклар) рәвешендә керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

«һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр һәм лицензия шартнамәләре буенча алынган керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

күчемсез милекне сатудан салым салына торган керемнәр, шулай ук милекне арендага бирүдән (наем, поднаем) кергән керемнәр турында белешмәләр  (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр (Россия Эчке эшләр министрлыгыннан);

Россия Федерациясе территориясендә гражданның шәхесен раслаучы элек бирелгән паспортлар турында мәгълүмат (Россия Эчке эшләр министрлыгыннан);

алына торган алиментлар турында белешмәләр (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса) (Россия Суд приставлары федераль хезмәтеннән);

гариза бирүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыннарында булуы турында мәгълүмат (Россия Җәзаларны үтәтү  федераль хезмәтеннән);

инвалидлык булу һәм аның төркеме турында мәгълүмат (булган очракта) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирүчегә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы куллану турында мәгълүмат (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

табигый бәла-казага яки башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә, шулай ук террорлык акты белән бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм суммалары турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган  керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан).

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне) үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булган очракта;

тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы;

документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылуы.

гаризаның мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелүе;

формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килми торган документларның тапшырылуы;

Идарәгә (бүлеккә) гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документларны (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.7.2. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтү) буенча хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында (социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә) күрсәтелгән тулы булмаган документлар пакеты тәкъдим ителсә;

социаль контракт һәм (яки) документлар (мәгълүматлар) нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гаризада дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнсә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

территориаль социаль яклау органына җитешмәгән документларны (мәгълүматларны) кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында эшләп бетерелгән гаризаны һәм (яисә) эшләп бетерелгән документларны (мәгълүматларны) территориаль социаль яклау органына кертү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату (яңарту) турында карар гариза бирүчегә ул сайлаган ысул буенча бирелә:

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

гаиләнең җан башына кереме уртача яки ялгыз яшәүче гражданинның кереме халыкның җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләменнән артуы;

гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданинның кереме аена 20 000 сумнан артып китүе (авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә (ялгыз яшәүче гражданнарга) социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә);

гадәттән тыш хәл (янгын, су басу, башка табигать афәте) датасыннан социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында гариза бирү аена кадәр 12 айдан артык вакыт узуы;

милектә башка торак бинаның (торак бинаның бер өлеше) булуы (авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә (ялгыз яшәүче гражданнарга) социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә);

гадәттән тыш хәл (янгын, су басу, башка табигать афәте) фактын раслаучы документлар (белешмәләр, актлар, бәяләмәләр) булмау (авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә (ялгыз яшәүче гражданнарга) социаль контрактсыз дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә);

билгеләнү турында гаризада һәм (яки) документларда (мәгълүматларда) дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган белешмәләр булуы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 25.12.2023 №1682 карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 30 пунктында каралган очрактан тыш;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль яклау территориаль органына социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) нигезләмәнең 19 һәм 20 пунктларында билгеләнгән срокларда тапшырмау;

агымдагы финанс елында яңа социаль контрактлар төзү өчен бюджет ассигнованиеләре булмау;

Нигезләмәнең 55 пунктында билгеләнгән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алучылар санына ирешү;

эш эзләү чарасы буенча билгеләү турындагы гаризаны караган вакытта гариза бирүчене эшкә урнаштыру;

гариза бирүченең (аның гаилә әгъзасының) гамәлдәге социаль контракты булуы;

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында карар кабул ителгәнче мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында гаризаны кире алу;

мөрәҗәгать итүченең социаль контрактка кул куюдан баш тартуы яки социаль контрактка яки социаль адаптация программасына кул куюга килмәве;

мөрәҗәгать итүченең социаль яклау территориаль органы алдында түләнмәгән бурычы, шул исәптән элек төзелгән социаль контракт шартларына ярашлы түләнгән акчалар буенча суд тәртибендә түләтелә торган бурычы булу;

мөрәҗәгать итүче һәм аның гаиләсе әгъзаларының социаль контракт нигезендә, шул исәптән ведомствоара комиссия карары нигезендә, дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында карар кабул итү шартларына туры килмәве;

гражданинның эшкуарлык компетенцияләрен үстерү өчен (шәхси эшкуарлык эшчәнлеген («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне) гамәлгә ашыру буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә), шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен укуны уңышлы узуын раслаучы сертификат яки башка документ алмавы.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен өстәмә нигезләр исемлеге (элек төзелгән социаль контрактның гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң 12 ай эчендә):

гражданинның авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән эш эзләү чаралары буенча тәмамланган социаль контракт һәм башка чаралар булу;

эш эзләү чарасы буенча элек төзелгән социаль контракт гамәлдә булган чорда хезмәт эшчәнлеген туктату (яңа яшәү урынына күченү сәбәпле кыскартылу, эштән алыну очракларыннан һәм башка җитди сәбәпләрдән тыш);

шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвен туктату яки шәхси эшкуар булмаган гариза бирүчене салым органында шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча элек төзелгән социаль контракт гамәлдә булган чорда һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәптән төшү;

шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән башка чаралар буенча элегрәк төзелгән социаль контракт шартлары нигезендә түләнгән акчаларны социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме алучы тарафыннан максатчан файдаланмау;

игътибарга лаек булмаган сәбәпләр аркасында социаль адаптация программасы чараларының социаль контракты нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алучының үтәмәве (вакытында үтәмәве).

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен өстәмә нигезләр исемлеге (Идарәгә (бүлеккә) тиешле шартлар килеп чыгуы турында билгеле булган айдан соң 12 ай дәвамында):

мөрәҗәгать итүченең социаль яклау территориаль органына элек төзелгән социаль контрактны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту һәм мониторинглау өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) тапшырмавы;

эш эзләү чарасы буенча элек төзелгән социаль контрактның гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң 12 ай эчендә хезмәт эшчәнлеген туктату (яңа яшәү урынына күченү сәбәпле кыскартылу, эштән алыну очракларыннан һәм башка җитди сәбәпләрдән тыш);

шәхси эшкуар буларак дәүләт теркәвен туктату яки шәхси эшкуар булмаган гариза бирүчене салым органында шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча элек төзелгән социаль контракт гамәлдә

булган срок беткәннән соң 12 ай эчендә һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәптән төшү;

шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чаралар буенча элек төзелгән социаль контрактның гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң 12 ай эчендә салым түләүләренең бөтенләй булмавы;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $7^{1-1}$ статьясындагы 1 пунктының 8 пунктындагы унберенче абзацы нигезендә күрсәтелә торган эшсез гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга ярдәм итүгә халыкның мәшгульлек органнарыннан бер мәртәбә финанс ярдәмен алуы (шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча чаралар буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәткәндә).

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук

аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Идарәнең (бүлекнең) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда

башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын үтәү;

Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алынырга мөмкин.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны

имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә, гариза Идарәгә (бүлеккә) теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле

үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

Дәүләт социаль ярдәмен, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гаризалар төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) шәхси эшкуарлык эшчәнлеген («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне) гамәлгә ашыру буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып барганда эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен тест узу;

5) эшкуарлык компетенцияләрен үстерү өчен укыту узу (эшкуарлык компетенцияләренең дәрәҗәсен билгеләү өчен тетны канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗә белән узу очрагында);

6) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын эшләү;

7) социаль контракт төзү – социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә;

8) дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

9) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә) бирү яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетта урнаштыру.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, Мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче электрон документ формасында бирелгән гариза (алга таба - электрон гариза) статусын, шулай ук үз инициативасы белән теләсә кайсы вакытта шәхси кабинетта алга таба гамәлләр кылу турында мәгълүматны карый ала.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты, җитешеп бетмәгән, мөрәҗәгать итүче ун көнлек срокта тапшырырга тиешле документлар (белешмәләр) исемлеге турында, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Идарәгә (бүлеккә) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече шәхсән, телефон, почта, электрон почта ярдәмендә мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә

ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларның күчермәләрен теркәп, Идарәгә (бүлеккә) социаль контракттан башка дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза тапшыра.

Социаль контракт төземичә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү турында әлеге Регламентның 1 кушымтасындагы форма буенча гариза биргән очракта, әлеге Регламентның 1.2 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өстәмә рәвештә әлеге Регламентның 2.6.1 пунктының 34-36 абзацларында күрсәтелгән документларны да тапшыралар.

Законнарда каралган тәртиптә расланган гариза һәм документларның күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында авторизацияләү уза;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гаризаның электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә.

Идарә (бүлек) белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Идарә (бүлек) белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан гаризалар булу-булмавын көненә 2 тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гариза почтадан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелгәндә, – гаризаны теркәү датасы һәм беркетелгән керү номеры турында хәбәр җибәрә.

Документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә.

Гариза һәм документларны почта аша һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алганда, Идарә (бүлек) белгече документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту турындагы карар белән гаризаны һәм документларны почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша кире кайтара.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать итеп, документлар (мәгълүматлар) тулы булмаган комплектын биргән очракта, Идарә (бүлек) гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гаризаны теркәгән көннән алып 10 эш көне эчендә өстәмә бирелергә тиешле документлар (мәгълүматлар) исемлеген бирә. Бу очракта хезмәт күрсәтү вакыты туктатыла.

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы ярдәмендә бирелгән булса, Идарә (бүлек) белгече гаризаны теркәгән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә гаризаны теркәгән көннән алып 10 эш көне дәвамында ул бирергә тиешле кирәкле документлар (мәгълүматлар) исемлеген үз эченә алган хәбәрне гариза бирүчегә Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша  җибәрә. Бу очракта хезмәт күрсәтү вакыты туктатыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентның 2.11 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләрне исәпкә алып, гариза һәм документлар алынган көнне, ә гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша эшләми торган яки бәйрәм көнендә алынган очракта, аннан соңгы беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында гаризада гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар (мәгълүматлар), гариза бирүче тарафыннан бетерелергә мөмкин булган дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булган очракта, белгеч мондый гаризаларны һәм (яки) документларны (мәгълүматларны) гариза бирүчегә төзәтергә тиешле мәгълүматны күрсәтеп, эшләп бетерү өчен кире кайтара. Бу очракта социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү турында  эшләнеп беткән гариза  һәм (яисә) эшләнеп беткән документлар (белешмәләр) тапшырылган көнгә кадәр, әмма биш эш көненнән артмаган чорга кадәр туктатып торыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү, мөрәҗәгать итүчегә эшләп бетерү өчен кире кайтарылган гариза һәм (яки) документлар (белешмәләр).

3.3.2. Мөрәҗәгать итүчеләр гариза һәм документларның күчермәләрен КФҮ аша тапшыра ала.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документлар теркәп, КФҮ гариза һәм документларны тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә (бүлек) белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү

белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать  җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.1.1. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

3.4.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

туу турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

туу турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

үлем турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

үлем турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә кору (аерылышу) турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан тиешле акт язуын теркәү очракларыннан тыш) (Федераль салым хезмәтеннән);

гаилә кору (аерылышу) турында мәгълүмат (тиешле актны чит ил дәүләтенең компетентлы органы теркәгән очракта) (Федераль салым хезмәтеннән);

опека һәм попечительлек органының балага опека яки попечительлек билгеләү турындагы карарында булган мәгълүматлар (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны (попечителе) турында мәгълүмат (чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан опека (попечительлек) билгеләнгән очрактан тыш) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында мәгълүмат, ата-ана хокукларын чикләүне бетерү турында мәгълүмат, баланың тормышына яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы алу турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

баланың эшчәнлек сәләтен чикләү яки ата-анасын яки башка законлы вәкилен эшкә сәләтсез дип тану турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

хезмәт яисә башка бурычларны, кызыксындыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, бүләкләү, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, граждан-хокукый шартнамә кысаларында, шул исәптән түләүле шартларда опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә (тәрбиягә бала алган гаилә турында шартнамә, патронат гаилә турында шартнамә) (шул исәптән салым тотып калынган) буенча гамәл кылган өчен алынган түләү турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

мәҗбүри пенсия иминияте турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда үлгән иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

уртача җан башына керем исәп-хисап чорында эшкә сәләтсез затларга Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән кайгыртуны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирү вакытына һәм (яки) гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр һәм җитештерү финанс инструментлары белән операцияләр (тотылган чыгымнарны исәпкә алып) буенча алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында белешмәләр, шулай ук оешма белән идарә итүдә катнашуга бәйле рәвештә дә (Федераль салым хезмәтеннән);

банкларда кертемнәр буенча процентлар (счетлардагы калдыклар) рәвешендә керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

«һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр һәм лицензия шартнамәләре буенча алынган керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

күчемсез милекне сатудан салым салына торган керемнәр, шулай ук милекне арендага бирүдән (наем, поднаем) кергән керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр (Россия Эчке эшләр министрлыгыннан);

Россия Федерациясе территориясендә гражданның шәхесен раслаучы элек бирелгән паспортлар турында мәгълүмат (Россия Эчке эшләр министрлыгыннан);

алына торган алиментлар турында белешмәләр (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса) (Россия Суд приставлары федераль хезмәтеннән);

гариза бирүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыннарында булуы турында мәгълүмат (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

инвалидлык булу һәм аның төркеме турында мәгълүмат (булган очракта) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан);

гариза бирүчегә һәм (яки) аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы куллану турында мәгълүмат (Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

табигый бәла-казага яки башка гадәттән тыш хәлләргә бәйле рәвештә, шулай ук террорлык акты белән бәйле рәвештә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар һәм башка чыганаклар акчалары исәбеннән түләнә торган бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм суммалары турында белешмәләр (вәкаләтле органнардан);

лотереяны оештыручылар, тотализаторлар тарафыннан һәм хәтәрлеккә нигезләнгән башка уеннардан түләнә торган, отыш нәтиҗәсендә алынган керемнәр турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан).

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021

елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен тест уздырганда – шәхси эшкуарлык эшчәнлеген («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне) гамәлгә ашыру буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә

3.5.1. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелгән очракта – Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша) эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен тест үткәрү датасы турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгәннән соң алты эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тест үткәрү датасы турында хәбәр ителгән.

3.5.2. Идарә (бүлек) белгече Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы билгеләгән мәгълүмат системасын кулланып, эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен гариза бирүчегә тест уздыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгәннән соң ун эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүченең тест нәтиҗәләре буенча йомгаклау мәгълүматлары (йомгаклау мәгълүматлары).

3.5.3. Эшкуарлык компетенцияләре дәрәҗәсен билгеләү өчен уздырылган тест барышында гариза бирүче канәгатьләнерлек нәтиҗә бирмәгән очракта, Идарә (бүлек) белгече гариза бирүчене (социаль контракт төзелгәнче) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын тәшкил итүче оешмаларда, шул исәптән «Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды» коммерцияле булмаган микрокредит компаниясендә, эшкуарлык компетенцияләрен үстерү өчен укытуга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләгән процедура тест узган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: укуны раслаучы сертификат яки башка документ бирү.

3.6. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә гариза биргәндә гаиләне социаль адаптацияләү программасын эшләү

3.6.1. Социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге белгече (алга таба – үзәк (бүлекчә)) гаризада күрсәтелгән ысул белән Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын эшләү өчен үзәккә (бүлекчәгә) мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гаризаны теркәү көненнән соң бер эш көне дәвамында, ә гариза бирүче укуны үткән очракта, гариза бирүче сертификат яки укуны үтүен раслаучы башка документ биргән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә үзәккә (бүлеккә) мөрәҗәгать итү кирәклеге турында хәбәр ителгән.

3.6.2. Үзәк (бүлекчә) белгече:

гариза бирүче белән берлектә Нигезләмәгә №2; №3; №4; №5 кушымталарда китерелгән формаларның берсе буенча Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын эшли;

Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләүнең эшләнгән программасын Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне, әмма гариза теркәлгәннән соң дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча, шәхси эшкуарлык эшчәнлеген («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне), шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыру буенча чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гаризалар буенча, – гариза теркәлгәннән соң 18 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү буенча эшләнгән һәм Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән Программа.

3.6.3. Идарә (бүлек) белгече социаль контрактны, гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын һәм бизнес-планны (шәхси эшкуарлык эшчәнлеген, һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне оештыруга социаль контрактлар төзегәндә) Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссиягә карау һәм раслау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптация программасын карау һәм раслау өчен юнәлдерелгән.

3.6.4. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын һәм бизнес-планны (шәхси эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга, һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлеккә социаль контрактлар төзегәндә) раслау турында карарны карый һәм кабул итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләүнең каралган һәм расланган Программасы.

3.7. Социаль контракт төзү – социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә

3.7.1. Идарә (бүлек) белгече гаризада күрсәтелгән ысул белән социаль контрактка кул кую өчен гариза бирүчене чакыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура ведомствоара комиссия тарафыннан Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасы расланган көнне башкарыла.

3.7.2. Нигезләмәнең 2 нче, 5 нче кушымталарындагы формалар буенча социаль контракт төзү.

Әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән процедура ведомствоара комиссия Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын раслау турында карар кабул иткән көннән алып ике эш көне эчендә башкарыла.

Нигезләмәнең 3 нче, 4 нче кушымталарындагы формалар буенча социаль контракт төзү.

Әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән процедура ведомствоара комиссия Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын һәм бизнес-планны раслау турында карар кабул иткән көннән алып җиде эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: территориаль социаль яклау органы, аның җитәкчесе һәм мөрәҗәгать итүче арасында төзелгән социаль контракт.

3.8. Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү

3.8.1. Идарә (бүлек) белгече:

әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 4 нче кушымтасындагы форма буенча дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

әлеге Регламентның 3.4 пунктындагы 3.4.1.2 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматларга нигезләнеп, ләкин әмма дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, шул исәптән авыр тормыш хәлен җиңүгә юнәлдерелгән эш эзләү чараларын һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә;

әлеге Регламентның 3.4 пунктындагы 3.4.1.2 пунктчасында күрсәтелгән алынган белешмәләр нигезендә ике эш көне дәвамында, әмма шәхси эшкуарлык эшчәнлеген («Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланганда һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне) гамәлгә ашыру чараларын гамәлгә ашыруга, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруга социаль шартнамә нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 27 эш көненнән дә соңга калмыйча;

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә – ике эш көне дәвамында, әмма гариза бирүчегә Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын эшләү өчен мөрәҗәгать итү кирәклеге турында хәбәр ителгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, ул Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданинны) социаль адаптацияләү программасын эшләү өчен килмәгән очракта;

социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә – ике эш көне дәвамында, әмма гариза бирүчегә социаль контрактны имзалау өчен гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрелгән чакыруны алганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әгәр ул социаль контрактны имзалау өчен килмәсә.

Процедуралар нәтиҗәсе: дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проекты, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проекты.

3.8.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында имзаланган карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында имзаланган карар.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар белән хәбәрне социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар белән хәбәрне гаризада күрсәтелгән ысул белән, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карар, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында карар турында хәбәр итү.

3.10. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.10.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карарның яңадан рәсмиләштерелгән проекты, шул исәптән Идарә (бүлек) җитәкчесенә имза куюга юнәлтелгән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында карар проекты.

3.10.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар проектын имзалый һәм аны Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар, шул исәптән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.10.3. Идарә (бүлек) белгече үзгәртеп рәсмиләштерелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарны, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарны мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән дәүләт социаль ярдәмен билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар, шул исәптән социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.10.4. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша күпфункцияле үзәккә Идарә (бүлек) тарафыннан бирелгән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда җибәрегән хәреф хаталарын һәм ялгышларны төзәтү турында язмача гариза тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

Идарәгә (бүлеккә) техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

Күпфункцияле үзәк белгече Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Идарәгә (бүлеккә) җибәрә.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла. Тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Идарә (бүлек) белгечләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Министр карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (оешма), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты (белгече) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк, «Интернет» челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru) файдаланып, Татарстан Республикасы порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм портал (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән

файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә граждан хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (учреждение хезмәткәренең) яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6.2. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсенә (бүлегенә)

________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза

Мин,
________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яисә законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
яши торган адрес:
________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры ________________________
түбәндәгеләрне күрсәтү турында үтенәм:
миңа (минем гаиләмә) (кирәклесе астына сызарга кирәк)
мөрәҗәгать итүчегә (ышанычлы зат мөрәҗәгать иткән очракта тутырыла)
________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)
түбәндәге адрес буенча яши:
________________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
________________________________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның исеме, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән орган атамасы)
дәүләт социаль ярдәме
________________________________________________________________________________,
(күрсәтергә: аз керемле гаилә буларак (аз керемле ялгыз яшәүче гражданин буларак);
________________________________________________________________________________,
авыр тормыш хәлендә булган гаилә буларак (ялгыз яшәүче гражданин буларак))

1. Тапшыра торган документлар (белешмәләр):

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

2. Гаилә составы:

| | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) | Туганлык мөнәсәбәтләре |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

3. Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр:

| | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) | Керем төре | Керем суммасы (сум) |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

4. Мөрәҗәгать итүченеке һәм аның гаилә әгъзаларыныкы булган мөлкәт турында белешмәләр:

| | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) | Мөлкәт төре | Милекчелек төре |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

5. Дәүләт социаль ярдәменең билгеләнгән суммасын (түләүне):
әлеге счетка күчерү юлы белән ___________________________________
(мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлекчәсе аша җибәрергә
__________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең яки законлы вәкилнең почта реквизитлары күрсәтелә)
Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм түләүләргә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым _____________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы)
Дөрес булмаган мәгълүматлар белән документлар тапшыру нәтиҗәсендә миңа артык түләнгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә кире түләттерелүе турында кисәтү алдым.
Мәгълүмат, шул исәптән дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, алуга риза:
почта адресы буенча язма формада: __________________________________________
____________________________________________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _________________________
(телефон номеры)
электрон почта адресы буенча электрон документ формасында
____________________________________________________________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы дәүләт һәм
муниципаль хезмәтләр порталы»
Татарстан Республикасы дәүләт
мәгълүмат системасындагы
шәхси кабинет аша ________________________________

Мөрәҗәгать итүче:
________________________________________ _______ «__» ________ 20__ ел.
(мөрәҗәгать итүченең яисә аның мәнфәгатьләрендә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) (имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде ________ 20__ ел.
_______ __________________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)
__________________________________________________________________________
Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәү номеры _______________
Документлар саны ______ данә, __ биттә.
Документларны кабул итте ________ _______ _______________ __________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

«Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның
аерым категорияләренә дәүләт
социаль ярдәме күрсәтү (бирү)
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
2 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| | Мөрәҗә-гать итү датасы | Мөрәҗә-гать номеры | Гражда-ниннның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта); | Адрес | Мөрәҗә-гать итү сәбәпләре | Мөрәҗә-гать итү нәтиҗәләре | Сәбәпләрен күрсәтмичә, мөрәҗәгать итү нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

«Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның
аерым категорияләренә дәүләт
социаль ярдәме күрсәтү (бирү)
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
3 нче кушымта

Форма

«_________________________________________»
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә:____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)

Элемтәгә керү өчен белешмәләр:
___________________________________
(Почта индексы һәм адрес)
______________________________

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында карар

«________» № «________»

«___________» № «________» гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителде:

________________________________________________________________________________________
Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (туу датасы)

«__________» башлап «__________» кадәрге чорга яки бер тапкыр «__________» күләмендә

Өстәмә мәгълүмат: «__________».

(«_____________» «____________») Электрон имза турында белешмәләр

Форма

«___________________________________»
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә: «_______________________________»
(фамилия, исем, ата исеме)

Элемтәгә керү өчен белешмәләр:
«________________________________»
(Почта индексы һәм адрес)
________________________________________

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында
КАРАР

«______» № «________»

«___________» № «________» гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителде:

«_________________», «____________»
Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) (туу датасы)

«__________» башлап «__________» кадәрге чорга яки бер тапкыр «__________» күләмендә

Өстәмә мәгълүмат: «_________________».

(«___________» «___________») Электрон имза турында мәгълүмат

Форма

«_________________________________________»
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә: «__________________________ »
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)
Элемтәгә керү өчен белешмәләр:
«__________________________ »
(Почта индексы һәм адрес)
«__________________________ »

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

«_________»                                                                                    № «_________»

«__________» № «_________» гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

- «__________________»;
- «__________________»;
- «__________________».

Өстәмә мәгълүмат: «___________________________ ».

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

(«______________» «______________»)          Электрон имза турында мәгълүмат

Форма

«___________________________________ »
(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә: «__________________________ »
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)
Элемтәгә керү өчен белешмәләр:
«_____________________________»
(Почта индексы һәм адрес)
«_____________________________»

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

«________»                                                            № «________»

«_________» № «________» гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

- «_________________»;
- «_________________»;
- «_________________».

Өстәмә мәгълүмат: «____________________________».

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

(«_____________» «_____________»)        Электрон имза турында мәгълүмат

«Татарстан Республикасы
территориясендә гражданнарның
аерым категорияләренә дәүләт
социаль ярдәме күрсәтү (бирү)
буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының социаль
яклау идарәсенә (бүлегенә)

_________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ___________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча күрсәтелә)

яши торган адрес

______________________________________________________________.

______________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

______________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

______________________________________________________________,

техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________

______________________________________________________________.

______________________________________________________________

______________________________________________________________,

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән ________________ №______________.

карар датасы карар номеры

Дәүләт хезмәте күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар алуга риза ___________________________________.

(шәхсән, электрон почта аша)

________________________________________ __________ «__» ________ 20__ ел.

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имзасы)

«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү (бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

«________________________________»

(вәкаләтле орган атамасы)

Кемгә: «______________________»

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

Элемтәгә керү өчен белешмәләр:

«______________________»

(Почта индексы һәм адрес)

«______________________»

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү (бирү) буенча хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

«________»                                                                                    № «________»

«_________» № «________»          гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча «Дәүләт социаль ярдәме» турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:
«____________» «____________» «___________» «____________» «______________»
«____________» «____________» «___________» «____________»

Өстәмә мәгълүмат: «______________________».

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

(«_____________» «_____________»)          Электрон имза турында мәгълүмат.